КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 16 февраль г.Казань № 110

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 318 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 26 октябрь, 507 нче; 2006 ел, 18 апрель, 192 нче; 2006 ел, 21 апрель, 199 нчы; 2007 ел, 7 ноябрь, 621 нче; 2008 ел, 28 март, 196 нчы; 2008 ел, 2 октябрь, 720 нче; 2010 ел, 28 октябрь, 864 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1042 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 17 март, 197 нче; 2011 ел, 13 сентябрь, 762 нче; 2012 ел, 16 март, 221 нче; 2012 ел, 24 март, 237 нче; 2012 ел, 6 август, 668 нче; 2012 ел, 26 декабрь, 1153 нче; 2013 ел, 31 гыйнвар, 54 нче; 2013 ел, 14 март, 161 нче; 2013 ел, 14 май, 323 нче; 2014 ел, 12 апрель, 238 нче; 2014 ел, 8 июль, 471 нче; 2014 ел, 8 август, 575 нче; 2015 ел, 10 август, 578 нче; 2015 ел, 24 декабрь, 969 нчы; 2016 ел, 22 гыйнвар, 32 нче; 2016 ел, 15 июнь, 405 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 702 нче; 2016 ел, 14 декабрь, 933 нче; 2017 ел, 2 май, 256 нчы; 2017 ел, 21 август, 595 нче; 2017 ел, 12 декабрь, 976 нчы; 2018 ел, 24 июль, 590 нчы; 2018 ел, 20 декабрь, 1196 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы (алга таба – Министрлык) мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендә дәүләт сәясәтен үткәрә торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы, мәгълүматлаштыру һәм мәгълүмат иминлеген тәэмин итү өлкәсендә (шул исәптән

критик мәгълүмати инфраструктура) Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы булып тора.

1.2. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә, кушымта нигезендә эшчәнлек төрләре буенча билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә оештыру-хокукый формасына һәм ведомство буйсынуына бәйсез рзвештә, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән хезмәттәшлек итә.

1.3. Министрлык карамагында «ИТ-парк» югары технологияләр өлкәсендәге технопарк» дәүләт автоном учреждениесе, «Комплекс-52» дәүләт бюджет учреждениесе, «Төбәкара компетенцияләр үзәге – Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе, «Татарстан Республикасы Мәгълүмат технологияләре үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе, «Иннополис шәһәрен үстерү фонды» автоном коммерциячел булмаган оешма бар.

1.4. Министрлык үз эшчәнлеген федераль дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары белән хезмәттәшлек итеп гамәлгә ашыра.

1.5. Министрлык үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе Президенты һәм Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм боерыклары, Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.6. Министрлык юридик зат булып тора, мөстәкыйль балансы, банк учреждениеләрендә исәп-хисап счеты һәм башка счетлары, үз исеме һәм Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәтләнгән мөһере бар.

1.7. Министрлык үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә товар базарларында көндәшлекне үстерү максатларының һәм бурычларның өстенлеген тәэмин итә.

1.8. Министрлыкның кыскартылган исеме – ТР Элемтә министрлыгы.

1.9. Министрлык урнашкан урын (юридик адресы): 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Кремль урамы, 8 йорт.»;

3.2 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мәгълүматлаштыру белән идарә итү (01.15*).»;

3.3.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«мәгълүмати иминлек торышын бәяләүне, мәгълүмати янаулар фаразлауны һәм ачыклауны, аларны булдырмау һәм аларның нәтиҗәләрен бетерүнең өстенлекле юнәлешләрен билгеләүне, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында мәгълүмати куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча чаралар комплексын планлаштыру, тормышка ашыруны һәм нәтиҗәлелеген бәяләүне тәэмин итә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин